Надпись на камне серого цвета длиной 50-60 см с пятью руническими знаками, расположенными ближе к правому нижнему краю камня. По характеру букв надпись Э.Р. Тенишев относит к XI-XII вв. Обнаружено В.Х. Хаковым 1967 году во время экспедиции в Лениногорском районе Татарстана вблизи деревни Сарабиккулово. Первым прочитал надпись сам В.Х. Хаков. Большую букву  относит символу. Рядом с символом находится первая буква, текст нужно читать слева - направо [6, с. 13]. И.Л. Кызласов знак  расценивает как тамгу [3, с. 68]. **В.Х. Хаков надпись прочел** *sübaš* т.е ***«глава войска, военачальник»*** [6, с. 13].

Э.Р. Тенишев вносит корректировку в чтение надписи: «Читать букву как ü недопустимо, для ü в западной рунике есть серия знаков. Следовательно, правильная версия *subaš* , т.е. *«источник реки».* Но есть ли в том месте река или русло иссохшей реки? Если есть, тогда чтение оправдано» [5, с. 161]. Э.Р. Тенишев предложил еще один вариант прочтения  справа налево. «Первую букву  можно читать как **š**, но и как č. Тогда получается поучительная надпись, состоящая из *(a)č «милость»* (встречается в одном из египетских памятников) и повелительной формы II л. мн.ч. от глагола *jasa «строй, делай, устраивай»* (встречается в большой надписи памятника Кюль-Тегину): *(a)č jas(a)ŋ*. «*Делайте добрые дела (милости)»*.

Предметы с руническими письменами свидетельствуют о том, что в Волжской Булгарии руническая графика употреблялась и после принятия ислама. Хотя существуют разночтения надписей, порою возникают споры об их языковой принадлежности, ученые склоняются к мнению, что язык поволжских рунических надписей имеют общетюркский характер, свидетельствует о ранней письменности татарского народа.

**Литература**


1. Fanuza Š.Nurieva. Old Turkic Runic Monuments of the Volga Area // Interpreting the Turkic Runiform Sources and the Position of the Altay Corpus/ Berlin, 2015. – S.112-122.
2. Кочкина А.Ф. Рунические знаки на керамике Биляра // Советская тюркология. – Баку, 1985. – №4. – С. 75-80.
3. Кызласов И.Л. Рунические письменности евразийских степей. – М., 1994. – 372с.
4. Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан, 1999. – 139б.
5. Тенишев Э.Р. Избранные труды. Книга первая. – Уфа, 2006. – 304с.
6. Хаков В.Х. Камень с рунической надписью из деревни Сарабиккулово Лениногорского района Татарии // Истоки татарского литературного языка. – Казань, 1988. – С. 12-13.



**Нурулла Гариф Гыйматдин улы,**

*тарих фәннәре кандидаты,*

*Биектау районы, Татарстан*

*E-mail: nur-garif@yandex.ru*



УДК 904


# ТАРИХИ ЧЫГАНАКЛАРДА ТӨРКИ-ТАТАР ИСЕМНӘРЕ ҺӘМ ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР

# ТЮРКО-ТАТАРСКИЕ ИМЕНА И ГЕОГРАФИЧЕСКИЕ НАЗВАНИЯ В ИСТОРИЧЕСКИХ ДОКУМЕНТАХ

# TURKIC-TATAR NAMES AND GEOGRAPHIC NAMES IN HISTORICAL DOCUMENTS


**Аннотация.** В статье исследуются тюрко-татарские имена и географические названия в исторических документах и летописях. Анализу поддаются исторические документы времен Казанского ханства. Особое внимание уделяется семантическим группам, которые отражаются в тюрко-татарских именах.



**Ключевые слова:** этнос, исторические документы, летописи, имена собственные, прозвища, географические

названия.

**Abstract.** The article studies the Turkic-Tatar names and geographic names in historical documents and chronicles. Analysis amenable to historical documents, the Kazan Khanate. The special attention is paid to the semantic groups, which are reflected in the Turko-Tatar names.

**Keywords:** ethnos, historical documents, chronicles, proper names, nickname, geographical names.

Татар халкының этник тарихын ачыклаганда еш кына каршылыклы фикерләр дә белдерелә. Бу каршылыкның бер өлеше халкыбызның атамасына бәйле чагылыш таба. Шул сәбәпле халыкны бүлгәләү тырышлыгы сизелә һәм “Без кемнәр?” дигән сорауга: “болгарлар, керәшеннәр, мишәрләр...” кебек җавап-шигарәләр дә ишетелә[6].

Татар халкы күп төрле кабилә-халыклардан тупланып оешкан. Милләтнең туплану тарихын ачыклаганда бер атама астында берләшкән кабиләләрдә кулланышта булган исем-атамаларны барлау һәм әлеге исемнәрне үзара һәм бүгенгеләре белән чагыштырып өйрәнү зур әһәмияткә ия. Шул сәбәпле, хезмәтебез татар атамасында берләшкән төрки кабилә-халыкларның тупланышын исемнәр аша ачыклау омтылышы эшчәнлегенә бәйле язылды.

Татар исемнәренең килеп чыгышына бәйле тикшеренүләр халкыбызның галим-галимәләр тарафыннан үткәрелгән. Алар арасында Гомәр Саттаров, Фирдәвес Гарипова, Гөлшат Галиуллина, Флүрә Мәҗитова, Зифа Әхәтова, Миләүшә Вәлиева, Зилинә Хөснуллина кебек милләттәшләребезне атап, алар тарафыннан язылган күп фәнни хезмәтләрне санап узарга була. Әмма бу өлкәдә эшләнергә, ачыкланырга тиешле мәсьәләләр күп әле.

Безнең тарафтан Казан ханлыгы чорына бәйле тарихи документлар һәм шул чорларга мөнәсәбәтле урыс елъязмаларында7 чагылыш тапкан кеше исемнәренә генә игътибар бирелде. Киләчәктә Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәрләре тарафыннан борынгы чорларга нисбәтле барлык тарихи чыганаклар да барланып, төрки-татар исемнәре тулаем туплансын иде. Шул очракта татар халкының этник тарихына бәйле тагын да нигезлерәк дәлилләнгән фәнни хезмәтләр дөнья күрер дигән фикердә калабыз.

Чыганакларда чагылыш тапкан исемнәр тупланышыннан күренгәнчә, төрки кабиләләрдәге кеше исемнәре ясалышына күп төрле факторлар йогынты ясаган. Аның иң тәүгеләре мәҗүсилек чоры яшәешенә бәйле кушылган. Мәҗүси заманнардан калган төрки-татар исемнәре: Таштимер, Тимер Хуҗа, Бай Тимер, Хушкилде, Асыл Хуҗа, Барбулсын, Тереугыл, Йомышчы, Таҗай, Таңатмыш, Таңчы, Якшылык, Халк(ы)аман, Куаныч, Сөендек, Сөенчек, Көньяхшы, Малтабар, Көнтуган, Көнтүбән,  Таңатар...

Кеше исемнәренең хайван атамаларыннан алынуы да мәҗүсилек чоры эзләре буларак кабул ителә: Карлыгач, Ябалак, Арыслан, Көчек, Елгыртай, Ала-тай, Лачын, Тургай, Җанбарс, Тутыйкош... Бу исемнәр аларның сыйфатларына (көчле, матурлык, җитезлек) бәйле кушылган.

Гади халык исемнәрендә аларның хезмәт эшчәнлеге дә чагылыш таба: Сабанчы, Балыкчы, Урманчы, Пычакчы, Остачы, Уракчы, Тимерясый һ.б. Халыкның яшәештәге рухи теләк-омтылышлары да исемнәрдә яңгыраш тапкан: Акыллы, Айтеләк, Таяныч, Тату, Миһербан, Тәвәккәл, Яхшыкалдым, Игелек,Куандык, Туганҗан, Харап-ура...

Исемнәренең бер өлеше борынгы кешеләрнең һәр нәрсәнең җаны бар дигән ышануларга бәйле барлыкка килгән. Шул сәбәпле төрки-татар исемнәрендә җан (җанның “кот” - сөенеч, бәхет, шатлык атамасындагы вариантлары да бар) атамасы кушылган исемнәр зур урын билән тора. Мәсәлән: Җанкуәт, Җанбарс, Җангали, Җанбай, Җанай, Җаныкай, Кадерлеҗан, Җанбулды, Җандәрвиш, Җансорый,Җанкүрә, Җаншәех, Җансәет, Җаныйбәк, Җанчура, Котлык, Котдус, Сөендек, Бәхеткилде һ.б. исемнәр шундыйлардан.

Исемнәр ясалышында табигатьтәге төсләр чагылышы да зур роль уйнаган. Шул сәбәпле төсләр тамыр кушымтасы буларак та катнаша. Мәсәлән: Ак – Ак, Акчура, Акбулат, Акбатыр, Ак-Балта, Ак-Казый, Ак-Солтан, Ак-морза, Ак-сәет, Ак Сәед, Ак-егет, Ак-Кылыч, Ак-Мөхәммәд, Акҗан, Аккол, Ак-дәүләт, Акҗәйләү...; Кара – Каракман, Карахуҗа, Паракүз, Каракөчек, Каракыз, Карамыш, Каранай, Карабаян, Карабулат, Карачура, Каракөчек...; Сары – Сары, Сарый, Сары батыр, Сарыкочкар... (Алакүз, Аккүз, Күккүз, Каракүз) һ.б.

Шулай ук исемнәрнең табигый үзгәреш, ел фасылларына бәйлелеге дә еш очрый: (Нишләде, ни эшли) – Капланды, Карачы, Нибулса, Елбулды, Елбулганда,Еляхшы, Яңгырчы, Янгур (Янгура)-Җангыр, Җантуды, Җанбакты... Төрки-татар атамаларында үзара бердәмлек, туганлыкны белгертүче атамалар да еш очрый. Мәсәлән: Оядаш (бер оядан), Бер-кан, Бидәш Имилдәш (Имидәш), Күбәк (Күбәү – бердәм мәгънәсендә), Тиңиш, Ишбулды, Иш-түрә, Иш-тирәк, Ишкәй, Ишем.

Төрки-татар исемнәре ясалышында, кушма компонент буларак, “Яр”, “Килде”, Бирде”, “Булды”, “Бакты” кебек тамырлар еш кулланыла: Яр – Аллаһ’яр, Ходайяр, Бәхтияр (Бәхетлеяр), Дәүләт’яр, Килдеяр, Хуҗамяр, Алдыяр, Әйдияр, Гамлеяр, Дан’яр, Данияр... Килде – Ураз (Ураза) килде, Дәүләткилде, Килде Казан, Җанкилде, Байкилде, Айкилде, Көнкилде, Таңкилде, Тиңкилде, Кышкилде, Бәхеткилде, Исәнкилде, Тәүгекилде, Аманкилде, Каилдебал(а), Килде-дус...

6 (2002, 2010 елларда уздырылган халык санын алу вакытында, сәяси фактор буларак, тарихта билгеле булган күп кенә төрки-татар кабилә атамалары да, милләт атамасы буларак, исемлеккә кертелде) http://www.perepis-2010.ru/documents/acts/ Приказ Росстата 2010г, № 74 и приложение №2.

2002 елда татарларны 45 төркемгә, 2010 елда 60-тан артык төркемгә бүлделәр. (Мәсәлән: татарлар, бортаслар, болгарлар, кыпчаклар, керәшеннәр, касыймлы, караимлы ногайлы һ.б. татарлар).

7 ПСРЛ. Т. IX-XIII, XIX, XX.и др.

Бирде – Аллаһбирде, Тәңребирде, Ходайбирде, Хәкимбирде, Куәтбирде, Хуҗамбирде, Бәхетбирде, Бирдебәк, Кәримбирде, Колбирде, Теләкбирде, Теләпбирде, Тагын Бирде, Мәмешбирде, Бәкләрбирде... Булды – Ишбулды, Барбулды, Җанбулды, Елбулды, Ялбулды, Такбулды... Бакты – Җанбакты, Кояшбакты, Байбакты, Ханбакты, Исәнбакты, Уразбакты һ.б.

Безнең эраның беренче меңьеллыгында, Алтай киңлекләреннән Еврапагача сузылган далаларда бихисап төрки кабиләләр тереклек иткән. Бу җирләр алар өчен "кайнап торган казан" ролен уйный. Бер кабиләләр икенчеләре йогынтысында калып эрегән. Төрле кабиләләрдән торган сәяси берләшмәләр туган. Бу "казанның" төп оеткысы булып төрки-татарлар торган. Төрле сәбәпләргә бәйле халыклар күченеше булган. Аларның тарихта иң билгелесе һуннар[8] күченеше.

IX–XVI гасырларда булып узган вакыйгаларны бәян итүче елъязмаларда искә алынган исем-атамаларның бер өлешенең кайсы халыкларга караганлыгы теркәлгән. Алардан күренгәнчә, бу чордагы тарихи вакыйгаларда төп рольне төрки кабиләләрдән саналган – **печәнәк**[9], бәрәнҗәр, кыпчак, болгар, төрки-татарлар уйнаган. Моның шулай икәнлеге исемнәр берлегендә дә чагыла. Мәсәлән, Тимер атамасына бәйле исем төрки халыкларның барысында да кулланышта булган: Темиръ – Тимер – *"князь Печенежсский",* (1004 нче ел). – ПСРЛ[10], –IX. – с. 68; Темиръ – Тимер – *"князь Половецкий",* (1152, 1155). – IX. – с. 195, 196, 200; Темиръ – Тимер – *"князь Ордынский",* (1471, 1485). – XII. – с. 124, 217; Темиръ – Тимер – *"сын хана Науруса, царевич Татарский",* (1360). – X. – с. 232.

Исемнәр уртаклыгын дәвам итәргә дә була: Бирдебәк – *"князь Половецкий",* (1155). – IX. – с. 200; Бирдебәк – *"воевода Батыя",* (1247). – XI. – с. 135; Бирдебәк, Җаныйбәк угылы – Алтын Урда ханы, (1347, 1359). – X. – с. 229, 230; (1378). – XI. – с. 33; Бирде-бәк – *"царев Татарский",* (1545). – XII. – с. 65; Айдар – *"князь Половецкий"*, (1268). – IX. – с. 236; Айдар – *"воевода Батыя"*, (1240). – X. – с. 116; Айдар – *"князь Ордынский"*, (1431-32). – XII. – с. 9, 15; Барак – *"князь Половецкий",* (1185). – X. – с. 11; Барак – *"князь Ордынский",* (1422-23). – XI. – с. 238; Көчек (Кечек) – *"князь Печенежсский",* (991). – IX. – с. 64; Көбек-углан, – *"князь Казанский",* (1555). – XX-2. – с. 182; Көбәк –*"хан Половецкий",* (1185). – X. – с. 11; Нибулса Көбәк –Хезмәтче татар, илче, (1533). – XX-1. – с. 540; Арыслан – *"посол Шемахинский"*, (1564). – XIII-2. – с. 371; Арыслан – *"князь Половецкий",*(1103). – IX. – с. 139; Алтын-көбә, Алтынапа(?) – *"хан Половецкий"*, (1099, 1103). – IX. – с. 135, 139; Алтын – *"хан Монгольский",* – XIV. – с. 32, 152; Алтын чеби (Алтынчы бәй?) – татар ханы Хозырның илчесе, (1360). – X. – с. 232; Алтынчәч,*"жена Бек-Булата Темгрюкова, царевича Астраханского",* (1561). – XIII-2. – с. 333; Сөенчегә, Сакал, Сөлек, Таш, Тугрыкан – *"князя Половецкие",* (1060-1127). – IX. – с. 92, 125, 125, 154, 173 һ.б.

Төрки кабиләләрнең бер тармагы, Төньяк Алтай биләмәләрендә яшәүче кыпчаклар – тарихи язмаларда безнең эрага чаклы I-нче меңьеллыкта ук искә алына. Соңрак, VIII-нче гасырда, кыпчаклар Кимәк каханлыгын төзүдә катнаша. IX гасыр уртасында кыпчаклар тарихында зур социаль-экономик һәм сәяси үзгәрешләр килеп чыга. Шул сәбәпле алар X-XI гасырларда Идел елгасының түбән өлеше белән Днепр арасындагы җирләргә күченәләр. Аларга чаклы бу җирләрдә бәҗәнәкләр белән төркиләр яши. Кыпчаклар басымы астында аларның бер өлеше чигенә, икенче өлеше кыпчаклар берләшмәсенә кушыла. Кыпчаклар яшәгән җирләр фарсы язмаларында "Дәште кыпчак", урыс елъязмаларында "Половецкая степь" буларак искә алынган.

Менә шушы урында, исемнәр охшашлыгына бәйле, бер тарихи вакыйганы искә алып узабыз.

Чыганакта монгол-татар явы башлыгы Батый искә алына. *(*Батый, Жучи хан угылы – Алтын Урда ханы, (1237-?). – XII. – с. 199). Аларга каршы, урыс кенәзлекләре белән берлектә кыпчак кабиләләре каршы чыга. Кыпчакларның башлыгы да Батый исемле *(*Батый – "князь Половецкий", (1225). – X. – с. 90).

Кыпчак даласына татар явы килүен ишеткәч, кыпчаклар урыс кенәзләренә килеп, *"татарлар элек тә безнең җирләребезне басып алды, берләшеп каршы чыкмасак, сез дә безнең хәлдә калырсыз"*, диләр. Кыпчаклар белән урыс кенәзләре берләшүен ишеткәч, татарлар урыс кенәзләренә илче җибәреп, *"без сезгә каршы түгел, үзебезнең колларыбызга каршы килдек, кыпчаклар элеккедән безнең атларыбызны көттеләр",* - дип, дәгъваләрен җиткерәләр. Урыс кенәзләре татарларның илчеләрен кыйнап җибәрәләр... Кыпчаклар белән урыслар Калка елгасы буенда татарлар тарафыннан җиңелүгә дучар булалар. Бу вакыйгалардан соң кыпчаклар Алтын Урда дәүләтенә керә һәм соңрак татар халкының бер компоненты буларак формалаша.

Ельязмада кыпчак кнәзе буларак Башкорт исеме дә чагылыш таба *(*Башкорт – "князь Половецкий", (1154). – IX. – с. 213; (1185). – XI. – с. 11).Башкорт атамасының кабилә башлыгы исеменә бәйле булуы да мөмкин. Аларның килеп чыгышы кыпчакларның күчеш чорында Урал таулары итәгендә аерымланып калган кабиләләренә тоташуы ихтимал.

Татар халкының вакыт агышында төрле дәүләтләр төзегәнлеге, тотканлыгы кеше исемнәрендә бик еш чагылыш таба*:* Дәүләтъяр, Исән Дәүләтбәхете, Дәүләтбирде, Төзер Дәүләткилде, Дәүләт-Гәрәй, Дәүләт-Солтан, Дәүләт-Хуҗа, Дәүләт Хаҗи, Ак-дәүләт, Дәүләт-нур, Дәүләт-Чура, Дәүләт, Дәү-ил, Дәү-өй...

Исемнәр төзелешендә иерархик титул һәм дини дәрәҗәләр аталышы зур роль уйный: Хан, Солтан, Карачъ-

8 Һуннар– күчмә кабиләләр берләшмәсе. Тарихчылар арасындагы төп фикер буенча нигездә төрки телле кабиләләрдән торганнар. Шулай ук фин-угыр компоненты да булуы ихтимал. Хуннулар белән турыдан-туры бәйләнешләре бар дип санала. Һуннар Көнчыгыш Аурупада б.э. IV гасырның җитмешенче елларында килеп чыгалар һәм зур дәүләт коралар. V гасыр урталарында алар арасыннан Аттила исемле бөек идарәче килеп чыга. Ул барлык һуннарны үз кулы астында берләштерә һәм Көнбатыш Аурупада сугышлар алып бара. http://tt.wikipedia.org

9 Печәнәк теле– төрки телле кабиләләрнең бер өлешен чагылдыра. Тарихи язмалар аша әлеге кабиләләр безгә печәнәк, үз, угыз, торк (төрк, түрк), кара каблык, ковый, төрпәй, баут, каспыч, беренҗәр һәм башка атамаларда билгеле.

10 Кыскартып язу сәбәпле, Рим цифрлары алдына торган ПСРЛ сүзе төшереп калдырылды.

Карачы, Бай-бәй-бәк, Морза-Мирза, Углан, Чура, Сәет, Шәех, Хажи, Хафиз, Мәүлә, Мулла һ.б. Алар кушма тамырлы кеше исемнәрендә беренче һәм икенче компонент буларак та, яисә үзара катнашудан да барлыкка килә: Сәет-бәк, Бай-морза, Морза-хан, Бикчура; Бай – Байбулат, Баймөхәммәд, Байдәүләт, Байсуфый, Байтирәк, Баем, Байбер, Байбичә, Байдар, Байгатаулла, Баймак, Байбәк, Байхуҗа, БайчураИделбай; Кол – Колгали, Колчура, Колсәет, Колмөхәммәд, Колшәриф, Колсарый, Колдәрвиш, Аккол, Тәңрекол, Колбирде, Җанкол, Ходайкол, Байкол, Кол Булмас; Чура – Акчура, Исәнчура, Җыенчура, Тиңчура, Чуракай, Бичура, Өнсәчура, Шаһчура, Чурагазый, Җанчура, Бикчура, Ябчура, Дәүләтчура; Хуҗа – Ак Хуҗа, Әхмәт Хуҗа, Аманхуҗа, Имамхуҗа, Байхуҗа, Сабыр Хуҗа, Хуҗаҗан, Хуҗашәех, Төбәкхуҗа, Күбәкхуҗа, Дәүләтхуҗа, *Асылхуҗа, Хуҗагали,* Бахты (Бәхетле) Хуҗа һ.б.

Төрки-татар атамаларында “Гәрәй” кушымтасы кергән исемнәр еш очрый. Бу бигрәк тә югары катлам кешеләренә (хан, солтаннарга) нисбәтле чагылыш таба: Мөхәммәдгәрәй, Баһадиргәрәй, Хаҗигәрәй, Үтәмеш Гәрәй һ.б. Әлеге атама сирәк кенә булса да гади кеше исемнәрендә дә чагылыш таба.

Төрки-татарлар арасында ислам дине таралышы исемнәрнең чыгышына тәэсир иткән. Исемнәрдә ислам диненә бәйле ай атамалары (Рәҗәб, Шәгъбан, Рамазан...), Аллаһыга, (Аллаһкүәт, Аллаһкол, Аллаһяр, Аллаһбирде, Аллагашөкер), аның аша Пәйгамбәрләргә (Йосыф, Якуб, Гайсә, Мөхәммәд) буйсыну, сыгыну, зурлау омтылыш ала. Ходайбирде, Тәңребирде,Тәңреколы кебек алмаш атамалар ясалышы да дәвам итә.

Язма чыганакларда төрки-татар хатын-кызларының исемнәре сирәгрәк искә алына. Әмма булганнарыда аларның гаҗәеп рәвештә әһәңле, матур яңгырашлы, мәгънәле булулары белән әсир итә. Хатын-кыз исемнәре: Байбиче – Байбичә – (1554). – XX-2. – с. 178. Горшадна – Гәүһәршад–*“Казанская царевна”*, (1531). – XX-1. – с. 531; Алтынчачь – Алтынчәч– (1561). – XIII-2. – с. 333. Чыганакларны күрсәтмичә генә әлеге исемлекне дәвам итәбез: Җанәкә,Яртуган, Гөл-Бостан (Хатын), Бикәч, Биби Зәгыйфә, Тәвәкәл, Дәүләт-Солтан, Татлы-би, Гөлбаһар, Күрекле-бикә, Ширин бикә, Сөен-бикә, Ак-бикәч, Бахшанда бикәч, Мөхсинә бикә, Малһурух, Мәрүана, Җанаш, Буҗуныл, Нази Мөлек хатун, Ай-кыз бикәч, Гөләби Йөз-бикә, Гәүһәр бикә, Көләчхан, Нәүрүз-Солтан, Нурсолтан, Рәҗәб-Солтан, Фатыйма Солтан, Биби (Аднаби) Ай-бикәч, Каракыз, Ханзадә,Толымбикә...

Тарихи чорларда төрки-татарларның бер өлеше урыслышуга юл тоткан. Бу процесс күп очракта мәҗбүри төс алган. Әлеге шәхесләрнең беренчел исемнәре билгесез булса да, чыганакта искә алынган шәхесләрнең татарлыгын белгертүче ясалма исем, фамилия кушамат яисә башка төр атамалар аерымлана. Мәсәлән: Новокрещенов, Новосельские, Новосильцов, Новосилец кебек исем-фамилияләр арасына төрки-татар исемнәре яшерелгән. Исемнәрдәге үзгәрешләр күп очракта чукындыру сәясәтенә бәйле барлыкка килгән. Мәсәлән: Петр *(“до крещения Кудайколъ”)* – Ходайкол, *“Татарский царевич”,* (1506, 1510). – XX-1. – с. 488, 497; Петр *(“до крещения Ярышты”)* – Ярышты, *“Татарский царевич”,* (1506, 1510). – XX-1. – с. 488, 497; Семенъ Бикбулатовичъ *(“до крещения Саин Булатъ”)* – Сөен Булат – Казан ханзадәсе, Касыйм ханы, *“в. кн. Тверской”,* – XIV. – с. 24, 25, 47, 68; Бахты-Хожа *(“в крещении Анания”)* – Бәхетле Хуҗа – *“постельничий Тохтамыша”,* (1391). – XI. – с. 125 һ.б.

Татар тарихына ачыклык кертүче тарихи чыгынакларның зур өлеше урыс елъязмаларыннан тора. Шул сәбәпле бериш исемнәрдә, өстәмә вариантбуларак, татарча исемнәрнең яңгырашы да сакланган: Мәсәлән: Одой (Адай, Атай, Ходай) – Одоевский; Обух (Абых)– Обухов (фамилия) һ.б.

Чыганакларда яңгыраш тапкан төрки-татар исемнәренең зур өлешен кушаматлар тәшкил итә. Татар исемнәре бер яктан кушамат буларак кыскарып үзгәреш кичерсә, икенче яктан әлеге кушаматлар гарәп һәм урыс теленең яңгыраш, үзенчәлекләренә бәйле бозылган. Кайбер очракларда аларның мәгънәсенә тулаем төшенү, ачыклау мөмкинчелеге дә калмый.

Кушаматлар: Мамай (Мәмеш, Мәмәд, Махмед) – Мөхәммәд, Камай – Камалетдин, Колай – Коләхмәт, Малей – Мәли (Малик) Шемай, Шамса – Шәмәй – Шәмси, (Шәмсетдин) һ.б.Бу уңайдан бер мисал. Татарча тулы исеме Баһаветдин, кушамат буларак: Баһау, Багыш, Баһдан буларак аталган. Урысча язылышта: тулы исем Боговитинович (Боговитиновъ), кушамат буларак: Богушъ, Бугушъ, Боуш, Богодан, Богдан дип йөртелгән.

Чыганакларда, кеше исеме буларак, аларга бирелгән кушаматлар да очрый: Кылый Гали, Тупас, Чуан Төмән, Йомык, Алабаш, Елый Бирде, Караҗан, Аксак Тимер, Тәбәнәк, Аңнамас, Артык. Мәсәлән, Мамайның (Олы Урда ханы) икенче исеме буларак язмаларда “Тетякъ” (Титәк, Тинтәк) атамасы күрсәтелә. Моны кушамат буларак та кабул итәргә мөмкин.

Төрки-татар исем-атамаларын өйрәнгәндә укучының игътибарын урыслашкан татарларның исемнәренә дә юнәлтәбез. Урыслашкан татарларның, бигрәк тә югары катламда торучыларның исемнәре, фамилияләренә күчеп, гасырлар кичкән. Иерархик баскычның түбәнге өлешендә торган, хезмәтче төрки-татарларның исемнәре бер ике буын арасында юкка чыккан.

Шунысы игътибарга лаек, елъязмаларда искә алынган урыс әсирләренең исемнәр күп очракта үзгәрмәгән, кушамат буларак та сакланган (Малай). Чувашлар (бу очракта ясаклы татарлар мәгънәсендә бирелә) әсирлектәге урыслар белән бергә искә алына. Алар халыкның түбән катламы буларак саналган. Шул сәбәпле исемнәре аталышында да азмы-күпме үзенчәлек сизелә. Безнең тарафтан XIV-XVI гасырның беренче яртысы арасында урыслашкан 500 гә якын[11] татар фамилияле шәхесләр ачыкланды. Татар исем-атамалы шәхесләр урыс кенәзлекләре иерархик баскычының

11 Бу исемлектә А.Х. Халиков тарафыннан язылган “500 РУССКИХ ФАМИЛИЙ БУЛГАРО-ТАТАРСКОГО ПРОИСХОЖДЕНИЯ” дигән хезмәттәге татар исемнәре өлешчә генә яңгыравыш таба. Безнең тарафтан Казан ханлыгы яулап алынганнан соң урыслашкан татарларның саны исәпкә алынмады.

зур өлешен алып торалар[12]. Татар исем-фамилияләренең бер өлеше, кыскарып, үзгәреш кичергән: Болгак (Булгак – Булгаковы), Урмат (Урмацкие), Нурма (Нурмөхәммәд) (Нормацкие), Шәрәф (Шарапъ), Исәнгали (Исленьев), Гәрәй (Кирей), Ширәмәт, (Шереметевы), Ширәй, Ширин, (Ширяевы) һ.б.

Тарихи чыганакларда географик атамалар: шәһәр, авыл, кыр-дала, елга, урман, тау-калкулы һ.б.) искә алынган. Безнең тарафтан 900 гә якын атама билгеләп узылды. Бер иш атамаларның урынын ачыклау һәм исемнәрне төгәл билгеләү кыенлыклар да тудыра. Төрки атамаларны урысча язылышында ә-а-е; г-к-х; , ж-е-з; я-ж; җ-з; з-с; аг-г-к; ас-с; о-а-у-ү, (мәсәлән: Алабуга-Елабуга, Урда-Орда, Олыс-Улус, Утар-Отар, Елантауы-Зилантова) һ.б. хәрефләр үзара алышып, яисә югалып атамаларның дөрес әйтелеше һәм мәгънәсе югала (Карасу елгасы – Корсунь, Тын елгасы – Дон, Ерык утравы – Ирихов остров, Гилдеево – Җанкилде, Шеланга – Чыршылы елга, Зөя – Свияга, Тәмте – Теньки, Җиде күл – Едигол (Семиозерка)...

Төрки-татар атамалары елъязмаларда урысчага тәрҗемә хәлендә дә бирелә: Хан болыны – Царский луг, Хан капкасы – Царевы (Царския) ворота,  Ханавыл – Царицыно, Царёв луг –Хан болыны, Царёво озеро –Хан күле, Царёвы тавруи–Хан кырыБиектау – Высокая Гора, Кунак (Сәүдә) утравы – Гостиный островъ, Чуртан күле – Щучье озеро, Мунча (Исле, Черек, Кара) күле – Банное (Поганое, Гнилое, Черное) озеро һ.б. Шул сәбәпле без әлеге исем атамаларның борынгы атамасын тәрҗемәи хәлдә кабул итәбез.

Югарыда билгеләп узганча, чыганакларда торак урыннары – шәһәр, авыл, ям һәм башка төр урыннар да искә алына. Авыл атамаларының күпчелек өлеше кеше исеменә барып тоташа: Карамыш, Тугаш, Дәвеш, Чураш, Апас, Балтач, Чытыш, Шәмәрдән, Килдеураз, Чыпчык, Шәле, Ишим, Тулыш, Уразбакты, Урак, Алабуга, Кырлай, Сасмак, Чур-ил... Аларның бер өлеше кыскарып, төрләнеп, урыс графикасына “кысылып”, танымаслык хәлгә дә килгән. Мисал буларак урыс атамасына яраклаштырылган Самосырово – Шәмәсер, Гилдеева – Җанкилде,  Аметьево – Әхмәт (Казан шәһәре биләмәсе), Янбат – Җанбулат (Саба районы) һ.б. авылларны күрсәтергә була. Мәсәлән, Казан кремленең Казан суы буенда урнашкан бер манарасының атамасы Елга буеннан–“Елбугины”га,икенчесе, Су буеннан – “Сбойливые”га әйләнгән.

Тарихи язмалар буенча ханнар, бәк-мирзалар һәм башка идарәчеләрнең исем-шәрифләренә бәйле авыл-утарлары атамалары да сакланып калган: Мәхмүтәк, Шаһгали, Ядегәр, Кошчак, Карамыш авыллары, Көрәеш (Көрәеш мирза), Әхмәт, Кадыш, бистәләре һ.б.

Авыллар атамасы башка төр очракларга бәйле дә кушылган. Мәсәлән, һөнәрчелеккә бәйле: Балыкчы, Уракчы, Балтачы, Бакырчы, Остачы. Кабилә атамасы буларак: Сабакүл, Тәмте, Чаллы, Бөрсет, Сон, Аты. Әһәмиятле вакыйгага бәйле: Яңа Сала, Бүләк (Билек?), Җиләкле алан. Елга атамасына бәйле: Бәтке,Гамбәрчәк, Ыргыз, Каеп һ.б.

Тарихи чыганакларда искә алынган төрки-татар атамаларның зур өлеше бүгенге чорда урыс атамаларына алыштырылган. Мәсәлән: Аккирмән – Белгород-Днестровский, Карасу – Елецъ, Саркыл – Белая Вежа, Җаек – Урал, Богородское.

## Әдәбият


1. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику / Отв. ред. М.Х.Гайнуллин. – М.-Л.: Изд. АН СССР, 1960. – 165 с.
2. Али Рахим. Татарские эпиграфические памятники XVI века // ТОИТ - Т. I. - Казань, 1930 – С. 145-175.
3. Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье / Отв. ред. А.Х.Халиков. – М.: Наука, 1981. – 282 с.
4. ПСРЛ. Т. XX. Ч. 1. Львовская летопись. – СПб., 1910. – 542 с.;
5. ПСРЛ. Т. XIII. Патриаршая или Никоновская летопись (Царственная книга). 2 пол. – СПб., 1906. – С. 303-533. – 8л. илюстр.; ПСРЛ. Т.XIV. Ч. 1. Повесть о честном житии. – СПб., 1918. – 285 с.
6. ПСРЛ. Т. XX. Ч. 2. Львовская летопись. – СПб., 1914. – 270 с.;
7. ПСРЛ. Т. XIII. Патриаршая или Никоновская летопись. 1 пол. – СПб., 1904. – 303 с. 8. ПСРЛ. Т.XII. Летописный сборник, именуемый Патриаршей или Никоновской летописью. – СПб., 1901. – 266 с.;
8. Шерифи Х. Зафер наме-и вилайет-и Казан // Предисловие и перевод с турецкого проф. Ф.Хакимзянова. Эхо веков – Гасырлар авазы – Казань, 1995. – № 1. – С. 83-92;
9. Алишев С.Х. Казан ханлыгы чорындагы татарча чыганаклар / Мөхәррире Әмирханов Р.Г. – Казань: Институт истории АН РТ, 2002. – 72 б
10. Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1551-1561 гг. Публикация текста / Сост. Д.А.Мустафина, В.В.Трепавлов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 391 с. ил. (IV (1551), V (1557-1561) книги).


---

12 Окинем теперь взглядом этнические корни и состав русской знати в целом (включая бояр и князей), какой она сложилась в семнадцатом веке. Согласно подсчетам Н.П. Загоскина, 229 русских аристократических фамилий были «западноевропейского» (включая немецкое) происхождения; 223 – польского и литовского; 156 – «татарского» и другого восточного. Против этих фамилий иноземного рода, 168 семей принадлежали к дому Рюрика; 42 были неутонченного «русского» происхождения и 97 фамилий – неопределенного. Некоторые из фамилий так называемого польско-литовского происхождения, скорее всего, являлись западными русскими. Тем не менее, фамилии русского происхождения составляли очевидное меньшинство. Цифры Загоскина относятся к более позднему периоду. Необходимо иметь в виду, что наплыв «татарских» фамилий в русскую знать сильно увеличился после правления Василия П.